СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ

ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 8 июленнән бирле чыга. | №93 (7266) | 3 август, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## „Уңыш-91“ пресс-группасы хәбәр итә

2 августта районда бөртекле культураларның 69 проценты теземнәргә салынды, 58 проценты, ягъни 31027 гектары суктырылды.

Хәзер төп көч сабан культураларын җыюга юнәлтелгән. Бүгенге көндә солының 31,5, арпаның 44 проценты җыелган. Бу—2629 һәм 1574 гектар дигән сүз.

Хуҗалыклар уҗым культуралары өчен җир әзерләүгә дә игътибарны киметмиләр. Ул 16917 гектарда әзерләнде. 6587 гектарда тунга сөрү үткәрелде. Уңышы җыелган 26883 гектарда, ягъни 50 процент күләмендә салам җыю үткәрелде, 17157 тонна салам эскертләргә куелды.

## *Кыр батырларына тигезләнегез!*

## Районның ашлык суктыруда иң әйбәт күрсәткечләргә ирешкән алдынгы комбайнчылары

Беренче багана—тоткан урыны, икенче механизаторның исем-фамилиясе, өченче—хуҗалык исеме, дүртенче—комбайн маркасы, бишенче урак башыннан 2 августка кадәр суктырылган бөртек (центнерларда).

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кыямов Х. К. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 6444 |
| 2. | Абрамов В. Д. | «Восход» | ДОН-1500 | 5997 |
| 3. | Донсков А. Е. | «Большевик» | ДОН-1500 | 5859 |
| 4. | Нилов Н. В. | Синдряков исем. | ДОН-1500 | 5400 |
| 5. | Хәлимов М. Х. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 4572 |
| 6. | Сафин Ә. Ә. | Ульянов исем. | ДОН-1500 | 4465 |
| 7. | Шәрәков Ф. Г. | «Алга» | СК-5 | 3784 |
| 8. | Гордюнин Ю. А. | «Заветы Ильича» | ДОН-1500 | 3721 |
| 9. | Абдрахманов Р. А. | «Игенче» | ДОН-1500 | 3700 |
| 10. | Хәсәнҗанов Н. Г. | «Чишмә» | СК-5 | 3655 |
| 11. | Ибраһимов Ә. И. | «Игенче» | ДОН-1500 | 3600 |
| 12. | Вафин Р. Р. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 3584 |
| 13. | Матвеев В. А. | «Алга» | СК-5 | 3563 |
| 14. | Абдуллин И. Ә. | «Рассвет» совхозы | ДОН-1500 | 3500 |
| 15. | Нуруллин Р. Ә. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 3364 |



Күңеле җиргә якын кешеләр генә авылга берегеп, җанын-тәнен авыл тормышына багышлый ала. Бикқол авылында мондый егетләр шактый. Мәктәптән үк трактор йөртү хокукына ия булып чыгалар да, чылбырлы трактордан башлап тырыш хезмәтләрен комбайнда, машинада күрсәтәләр. Васыйл—шундыйларның берсе. Кышын тракторда, елның җылы фасылларында комбайнга утыра.

Яшь гаилә атасын җиргә игътибарсызлык, әрәм-шәрәм итүләр нык борчый, күрәсең, авыл хуҗалыгында эш методларын үзгәртү җилләре килгәч, ул аларны шатланып каршы алды. Бүгенге көндә икенче ел инде хуҗалыкта оешкан ике аренданың берсенә җитәкчелек итә. Әйтергә кирәк, коллектив яхшы гына нәтиҗәләргә ирешеп килә.

Рәсемдә: «Таң» колхозы комбайнчысы Васыйл Сөнгатуллин.

## Беренче кичерешләр

Профессиям буенча шофер идем, быел исә беренче мәртәбә комбайн штурвалы артына утырдым. Беренче кичерешләр әйтеп бетергесез. Җитмәсә янәшәндә генә «ДОН-1500» комбайнында Юрий Казаков, «Нива» комбайннарында Николай Кашаев, Вениамин Ермушкин кебек тәҗрибәле һәм мактаулы комбайнчылар эшләгәндә. Быел уңыш әлләни югары булмады, ләкин булганын да югалтуларсыз һәм әрәм-шәрәм итмичә җыеп алу теләге белән зур тырышлык куябыз.

Колхоз да безне игътибар үзәгендә тота. Комбайнчылар өчен материаль кызыксындыру чаралары каралган, кырга кайнар аш китерелә. Аннан, шушы көннәрдә район культура йорты җитәкчелеге оештырган агитбригада да килеп китте. Үзебезнең Якушкино авылында туып үскән Светлана Федоровна Захарованың җырлавын аеруча яратып тыңладык. Галина Калукова да һәркемнең игътибарын җәлеп итте. Әлфия Таджибаева исә аеруча матур бии икән.

Кырда һәр туган яңа көн үзенчәлекле, бер-берсенә охшамаган. Шуңа да ул төрле тәэсирләр тудыра, күңелдә матур кичерешләр калдыра.

**В. НИКОЛАЕВ.**

«Заря» колхозы.

## Басуда кызу көннәр

**«Комбайн» колхозы.** Комбайнлылар 277 гектар мәйданда солы һәм 300 гектарда арпаны суктыруга керештеләр. Бүгенге көндә басуда 13 комбайн эшли.

Аеруча тырышлардан Әсхать Баһаветдинович Әхмәтов һәм Мансур Мөслихович Шәвәлиев саналалар. Алар урак башланганнан бирле «Нива» комбайннарында барлыгы 3240—2920 центнер ашлык суктырдылар. Быел Әсхать Баһаветдиновичның улы Марс та кыр корабына утырды. Хәзергә ул әтисенең иске комбайнында эшләп торса да, аңа шундый зур ышаныч күрсәтүләренә куанып бетә алмый.

**Ф. ӘГЪЛӘМОВА,**
баш бухгалтер.

## Дан флагы җилферди

**Район үзәгендә Дан флагы соңгы өчкөнлек нәтиҗәләре буенча «40 лет Победы» колхозы комбайнчысы Хәмит Кашапович КЫЯМОВ хөрмәтенә күтәрелде. Ул үзенең «ДОН-1500» комбайнында 6444 центнер ашлык суктырып, район комбайнчылары арасында әйдәп бара.**

## *Урып-җыю ничек бара?*

**Район хуҗалыкларында бөртекле культуралар җыюның барышы (процентларда). Мәгълүматлар 1991 елның 2 августына.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| Синдряков исем. | 57 | «Чишмә» | 54 |
| Ульянов исем. | 61 | «Таң» | 48 |
| «Правда» | 45 | «Москва» | 59 |
| «Восход» | 50 | «Үрнәк» | 77 |
| Мичурин исем. | 66 | «Лесная Поляна» | 52 |
| «Россия» | 70 | «Кондырча» | 81 |
| Хафизов исем. | 75 | Кузнецов исем. | 55 |
| «Путь к коммунизму» | 45 | «Заря» | 65 |
| Муса Җәлил исем. | 54 | «Чирмешән» | 61 |
| «Родина» | 56 | «Ленинский путь» | 58 |
| «Игенче» | 55 | «Беренче май» | 50 |
| «Большевик» | 60 | «Төрнәс» совхозы | 48 |
| «Заветы Ильича» | 54 | «Мамык» совхозы | 63 |
| «Знамя Октября» | 56 | «Рассвет» совхозы | 62 |
| «Алга» | 63 | «Сөлчә» совхозы | 43 |
| «Комбайн» | 53 | Хуҗалыкара берләшмә | 38 |
| XXI партсъезд исем. | 61 | «Яшь көч» | 70 |
| «Татарстан» | 74 | | |
| «40 лет Победы» | 63 | Район буенча | 58 |

## Яшел азык кайта

**«Игенче» колхозы.** Биредә мул итеп терлек азыгы хәзерләүгә җитди әһәмият бирелә. Бүгенге көнгә хуҗалыкның азык базасына 15 мең 800 центнер яшел масса салынды инде.

Басуда катнаш азыкны КСК-100 комбайннарында Рәис Фәйзетдинов, Ислам Галимов урдыралар. Вакылап тапатылган массаны исә ЗИЛ-130 машинасында Фәнил Закиров, КамАЗда Ислам Шәһапов һәм ЗИЛ-157 машинасында Наил Гафуров ташып торалар. Шулай итеп өзеклекләргә юл куелмый.

**В. КАНӘФИНА,**
экономист.

## РЕМОНТ БАРА

**«Рассвет» совхозы.** Бу арада совхозның Фәрит Фәйзуллин, Харис Лотфуллин, Минталип Вәлитов һәм Таһир Сатдаров җитәкчелегендәге төзүчеләр бригадалары товарлыклы-сөтчелек фермаларын ремонтлау белән мәшгульләр. Ремонтчылар тырышлыгы белән беренче һәм икенче бүлекчәләрдәге бозаулар һәм контроль сыерлар абзарларында стеналар яңартылды, идәннәр алыштырылды, түбәләр ябылды, шулай ук транспортерларны көйләү-төзәтү эшләре дә алып барылды.

Бригада болай төзү материалларына мохтаҗлык сизми, тик менә такта юнәтү генә бераз кыенга төшә.

Ферманы реконструкцияләү эшләрен төзүчеләр бригадасы 20 августка тәгәлләргә исәпли.

**Җ. ШӘРИПОВ,**
бригада эшчесе.

## 3 мең чиген үтте

**«Чирмешән» колхозы.** Хуҗалык комбайнчылары арасындагы хезмәт ярышында Габделәхәт Гыйлемханович Гобәйдуллин әйдәп бара. Ул үзенең «ДОН-1500» комбайнында урак башыннан бирле 3 мең центнер ашлык суктырды.

Габделәхәт Гыйлемхановичның бу уңышы очраклы түгел. 8 нче классны тәмамлауга, абыйсы Гәрәйхан янында комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгән иде ул. Хәрби хезмәттән кайтып МТЗ-80 тракторына утыргач та 5 ел буе җәйләрен кыр корабында ярдәмче булып эшләде. 1987 нче елда үзенә мөстәкыйль рәвештә СК-5 комбайны алды. Тәҗрибә һәм тырышлык үзенекен итте, егет шул елны ук район комбайнчылары арасында җиңеп чыкты, бүләккә «Урал» мотоциклы алды. Инде хуҗалыкка мәһабәт «ДОН-1500» кайткач, аны һич шикләнмичә Габделәхәткә тапшырдылар. Хәзер һәркем шатлана: ышаныч күрсәтеп ялгышмаганнар, узган ел 11600 центнер ашлык суктырып районда 4 нче урынны яулады. Инде менә быел да апасының малае Рифкать Йосыпов белән әйбәт кенә эшләп килә.

Башта уҗым культуралары, борчак җыюда булдылар, инде арпа суктыруга керештеләр. Аны теземнәргә салу шушы көннәрдә генә тәгәлләнде әле. Бу эшне Сабирҗан Хәсәнович Минheголов, Таһир Гәрәевич Әбделвәлиев башкардылар. Хуҗалыкта гомумән ашлыкны теземнәргә салуның төп өлеше аларга төште. Инде пенсиядә булса да кыр корабын ташламаучы Сабирҗан Хәсәнович исәбендә 300 гектар урылган иген исәпләнә.

Таһир Гәрәевич адресына да мактаудан кала сүз юк. Ул үзе сарыкчылыкта эшли. Әмма һөнәрлене тиз таныйлар бит: чәчүдә тракторга утырталар аны, уракта комбайнга һәм һәр җирдә дә күңел биреп эшли ул.

Колхоз комбайнчылары арасында тәҗрибәле игенче Хәсәнша Мөбәрәкшинович Гатин икенче урында бара. Аның исәбендә 2 мең центнерга якын суктырылган ашлык исәпләнә.

**Г. САДЫЙКОВА.**

## Хәсәнҗанов алда

«Чишмә» колхозында арыш һәм борчак урып-җыю тәгәлләнде. Арыш чабуда Н. Билданов, теземнәрне җыеп суктыруда элеккечә үк Н. Хәсәнҗанов алда бара. Алар—урак батырлары. Иптәш Хәсәнҗанов «ДОН-1500» комбайны бункерыннан 3274 центнер ашлык бирде.

Айдар Билданов СК-5 комбайнында 2212 центнер ашлык суктырды. Хуҗалык буенча һәр гектардан 20 центнер арыш, 6,2 центнер борчак уңышы алынды.

**К. ИЗМАЙЛОВА.**

# 4 август—Тимер юлчылар көне

## «Һәрнәрсә урынына басар»

**Норлат шәһәре станциядән башланган. Аның иң беренче эшчеләре дә тимер юлчылар. Бүген шул һөнәр ияләренең профессиональ бәйрәме—«Тимер юлчылар көне» нинди шартларда үтә, бәйрәмгә алар нинди рухта киләләр? Нәкъ шул хакта газета корреспонденты Ф. Галимова станция начальнигы Л. Н. ГАЗИЗУЛЛИНА белән әңгәмә корды:**

—Профессиональ бәйрәмебез булса да элеккечә мактанып, зур саннар белән коралланып, эшчәнлегебезне күккә чөя торган заманнар артта калды, әлбәттә. Синең план үтәлешенә карата кибет тулы әйбер булса иде. Быелгы бәйрәмгә исә тимер юлчылар зур борчу һәм кыенлыклар белән киләләр. Илебездә хөкем сөргән катлаулы шартлар: забастовкалар, республикаларның яңача яши башлавы еллар буе тотрыклы гына эшләп килгән станциягә нык тәэсир итте. Кинәт кенә вагоннар килүе кимеде. Соңгы кварталда тиешле 3000 тонна йөк төялмәде. Машина төзү заводы (аларга металлурглардан металл, ә икенчеләренә шахтерлардан кокс килмәү сәбәпле), ит комбинаты, «Вторчермет»—болар безне җайсыз хәлдә калдыручы предприятиеләр.

**—Чыннан да хәлегез көнләшерлек түгел, ә менә яңа үзгәрешләр, базар экономикасы, республиканың мөстәкыйльлеккә баруы сездә ничегрәк чагыла?**

—Без бит дәүләт дотациясендә яшибез, шуңа күрә базар экономикасына күчү әлләни тәэсир итмәде. Бары тик эш хаклары гына артты: эшчеләрнең 60, җитәкчеләрнең 40 процентка. Суверенитет мәсьәләсендә, бүгенгә Көньяк Урал вак таш җибәрүдән баш тарта, Ульянов өлкәсеннән цемент чикләнгән күләмдә килә, урман материаллары килү кимеде. Тик шундый кыенлыклар исәбенә булса да, республика мөстәкыйльлекне яуларга тиеш, минемчә. Үз халкын киендереп, ашатырлык дәрәҗәдә яшәргә тиеш. Ә халык бит искиткеч ярлы.

**—Сез бу хәл белән Татарстан Югары Советы депутаты буларак турыдан-туры таныштыр, мөгаен.**

—Әлбәттә. Эш бүлмәмә халык агымы бер дә тынмый, күбесенчә картлар. Кемдер шифер таба алмый, кемгәдер тәрәзә пәрдәләре кирәк. Болары ярар инде, әле бер әби, кунак килде, бер пачка шикәр табып бирегез, дип килгән иде бер көн. Һәркайда юклык.

**—Любовь Никифоровна, бу яктан тимер юлларның торышы ничек? Искеләрен яңартып, гамәлгә ярамаганнарын алыштырырга мөмкинлегегез бармы?**

—Бу—чишелмәгән, авыр мәсьәләләрнең берсе. Юлларга ремонт җитеңкерәми, чөнки материал юк, кайбер җирдә линияләр, уклар гамәлдән чыга, алыштырырга яңалары юк. Шул ук вагоннарның торышы да куандырмый, ватык килеш йөриләр. Яңаларны җитәрлек дәрәҗәдә чыгармыйлар.

Болар һәммәсе дә тимер юлында зур куркыныч тудыра.

**—Шундый катлаулы шартларда, эш белән тотрыксыз тәэмин ителеш эшчеләргә тәэсир итәме?**

—Тимер юл узелында 19 бүлекчә. Шуларда 1300 кеше эшли. Тагын 700 кеше пенсионерлар. Әйтергә кирәк, коллектив элеккечә бердәм. Киләчәктә бөтен кыенлыкларның җайланасына өмет белән, оптимистик рухта эшлиләр, һәрнәрсәнең үз урынына басуына ышаналар.

Безнең тимер юлчылар Куйбышев тимер юлында техника куркынычсызлыгы буенча беренче урында торалар. Тимер юлчы өчен бу бик әһәмиятле. Бездә шулай ук травмалар да, брак та юк.

**—Бу хәтәр һөнәр ияләренең яшәү шартлары турында да беләсе килә. Поселокны төзекләндерү чаралары күреләме?**

—Поселоктагы халык иң элек юлсызлык һәм сусызлык белән җәфа чигә. Үзегез күрәсез, соңгы елларда урамнар асфальт белән түшәлде. Бу эшләр хәзер дә бара. Су башнясы төзелә. Тик барысы да бик зур кыенлыклар белән әкрен темпларда бара. Эшчеләрнең яшәү шартларына килгәндә, соңгы 10 елда ике 90 фатирлы йорт төзелде. Әлбәттә, болар бик аз. Калган йортлар поселокта иске, бернинди уңайлыксыз бит. Киләчәктә ике фатирлы йортлар төзүне кулайрак булыр дип уйлыйбыз. Менә быел эшләгәнебездән 10 процент үзебезгә калачак. Шуңа өметләнеп, көнкүреш хезмәте күрсәтү йорты төзү мәсьәләсен куябыз. Ярдәмче хуҗалык оештыруны күздә тотабыз.

**—Безнең вокзалның хәле дә күңелле хисләр калдырмый бит. Яңа вокзал салу турында сүз кузгатылмыймы?**

—Планда каралганча, ул 1992 елдан башланачак. Ә хәзергә без күченү хәстәрен күреп йөрибез. 170 мең сумлык капиталь ремонт үткәрергә килешү төзедек. Ул якынча алты айга сузылачак әле.

**—Любовь Никифоровна, иң мөһим мәсьәләләргә кагылып киттек бугай. Ә бәйрәмнәрне ничек үткәрәсез соң?**

—Без бит график буенча эшлибез. Шуңа күрә кемдер эшли, кемдер ял итә. Ә бәйрәмне үткәрергә ел саен Чирмешән буена төшәбез.

**—Бәйрәмегез белән сезне! Алдыгызда торган кыенлыкларны җиңеп чыгарга язсын.**

---

## СЫНАУЛЫ ЕЛЛАРДА

**Б**ЕРЕНЧЕ тимер юллар барлыкка килгәннән бирле гасыр ярым вакыт узды. Бүген тимер юлларның дөнья челтәре—планетада транспорт системасының иң әһәмиятле звеносы. Ул 1,1 миллион километрга сузылган. Күчерү, ташу процессын оештыруда һәм тизйөрешле пассажир хәрәкәте үсешендә уңышка ирешкән илләр заманча фәнни-техник прогресс казанышларын кулланып корыч магистральләрнең автотранспорт һәм авиациягә конкурент булырлык сәләтен ачыкладылар.

Безнең илдә корыч магистральләр челтәренең суммар озынлыгы 146,1 мең километрга җитә. Ул дөньядагы тимер юлларның 12 процентын гына тәшкил итә.

Агымдагы елда корыч магистральләр хуҗалары үзләренең традицион профессиональ бәйрәмнәре—«Тимер юлчылар көне»ен 56 нчы тапкыр каршы алалар. Илнең иң мөһим транспорт конвейерына бүген бик катлаулы шартларда эшләргә туры килә. Сәяси системасы яңарган, килеп туган социаль һәм экономик проблемалары чишелә торган чорда тимер юл транспорты да зур роль уйнарга тиеш.

Ульяновск депосының Норлат филиалы коллективы елдан-елга тотрыклы рәвештә планнарын үтәп килде. Ләкин 1990 елда һәм 1991 елның ярты елында бу хәл кискен үзгәрде. Илдәге тотрыксыз шартлар, Кавказ арты, Молдова, Балтыйк буе республикаларындагы хәлләр безнең депога да тәэсир итте, чөнки алар илдә промышленность продукциясен җитештерүне киметтеләр, ә бу үз чиратында барлык төр йөкләрнең ташылуын азайтты. Шуңа күрә планнар үтәлмәвенә тимер юлчылар һич тә сәбәпче түгел. Җаваплылык һәм аңлылык ягыннан тимер юлчылар башка һөнәр ияләреннән бер башка өстен торалар, чөнки бу транспорт төре туктаса, шактый куркыныч янар иде.

Депо филиалы коллективы элеккечә бердәм, тырыш булып кала бирә, поездлар хәрәкәт куркынычсызлыгын тәэмин итеп килә. Филиалның уңышы аерым-аерым һәркемнең тырышлыгыннан җыела бит. Бәйрәм алдыннан аеруча машинистлар К. А. Демидов, А. З. Садретдинов, П. Д. Семочкин, Ю. Ю. Ильялов, В. Н. Петров, Е. В. Феоктистовны җылы сүзләр белән телгә аласы килә. Алар поездларның тоткарлыксыз йөрүен тәэмин итеп, индивидуаль йөкләмәләр исәбенә планны арттырып үтәүгә, дизель ягулыгын экономияләүгә ирешәләр. Алар белән бергә хәрәкәт куркынычсызлыгы буенча җәмәгать инспекторлары Э. У. Сабиров, А. А. Малыгин, А. М. Валегжанов, А. И. Хөсәенов, В. М. Казаков, П. Н. Ореховны мактап үтәргә кирәк. Алар ярдәмендә ничәмә тапкыр поезд һәм маневр эшләрендә брак җибәрелү куркынычы кисәтелде.

Шулай ук техник-расшифровщик Н. М. Чекмарева, төзү группасы бригадиры Н. Г. Стажаров, нарядчылар Ф. А. Федоренко, З. Е. Захарова, В. М. Давыдова да, һәрвакыт мактауга лаек тимер юлчылар.

Депо филиалының эшендә запастагы базаның МПС, ягулык склады һәм Норлат станциясенең бригада йорты коллективлары да әһәмиятле өлеш кертәләр.

Алда филиалны зур һәм җаваплы эшләр көтә. Көзге чор, яшелчә, җиләк-җимеш, яңа урып-җыю уңышын ташуның кызу вакыты. Кышкыга ягулык һәм имал, промышленность һәм авыл хуҗалыгы товарлары белән дә тәэмин итәргә һәм җитәрлек хәстәрләп калдырырга кирәк. Һәр тимер юлчының нәтиҗәле һәм тотрыклы хезмәте генә бу сынаулы елларда алда торган бурычларны җиңәргә ярдәм итәр.

**Р. ШӘРӘФЕТДИНОВ,**
машинист-инструктор.



«Тимер юлда үз һөнәренә береккән, аңардан башка үзен күз алдына да китермәгән кешеләр генә эшли ала»,—дигән сүзләр —Ульяновск депосының Норлат филиалында күпләрнең фикере. Шулайдыр да, филиал яхшы яшәү шартлары белән кызыктырмый, эше авыр, сигез сәгать кенә түгел бит, рейсыннан кайтмыйча ял юк. Эш хакына гына кызыгып килүчеләр (әле ул да бит заманына карап, чагыштырмача гына) озак тормыйлар, яңа, җайлырак эш эзләп китәләр. Ә менә машинист ярдәмчесе Александр Петрович Овчинников 1979 нчы елда бер килгәч, шуннан китмәде, берегеп эшли. Баштан укучы булып йөрде. Александр тормышта аралашучан кеше, спортчы, футболны ярата, үзе дә уйный. Бәйрәм алды көннәрендә дә кәефе күтәренке.

Рәсемдә: А. П. Овчинниковның чираттагы рейска китеп барышы.

## Машинист һөнәрен—буыннан-буынга

Ульяновск депосының Норлат филиалында эшләүчеләрнең байтагы үз һөнәрләрен буыннан-буынга күчерәләр. Федоренко, Хөсәенов, Щавелев—биредә иң еш ишетелгән фамилияләр, мөгаен, шулардыр.

Владимир Афанасьевич Федоренко гаилә башлыгы— машинист, Вера Алексеевна, аның иптәше—нарядчы, уллары Юрий әтисенең һөнәрен сайлаган.

Ислам Ибраһимович Хөсәенов (хәзер мәрхүм) кече яшьтән гомерен шунда үткәрә, уллары Әмир һәм Рөстәм дә әтиләре кебек машинистлар.

Николай Георгиевич Щавелевның атасы да шунда эшли, үзе машинист. Бабасы, атасы башлаган бу һөнәрне аның улы Георгий Николаевич дәвам итә.



## Барыннан да элек—уяулык

—диләр тимер юлда. Машинист Александр Петрович Мартюшин нәкъ шул яктан үзен танытты да. Ул күптән түгел бер барып кайтуында Норлат—Бөгелмә участогының бер җирендә юлның төзексезлеген күреп, һәлакәттән коткара.

Петр Дмитриевич Семочкин да нәкъ шул яктан үзен күрсәтте. Алар Константин Алеексеевич Демидов белән икесе юлларда хәрәкәт куркынычсызлыгын тәэмин итүләре өчен Куйбышев тимер юл начальнигы тарафыннан Почет билгесе белән бүләкләнделәр.

## Тәмле дә соң ипие

Тимер юл ипие: Октябрь районы халкы өчен шулай әйтү дә, йомшак, кабарып торган, хуш исле, гаҗәеп тәмле ипине күз алдына китерергә сәбәпче була. Аны халык иң оста пешерүче кул астыннан чыккан, мичтә пешкән авыл ипие белән тиңли. Кайнар икмәкне сатып алгач, эх башкалары да шулай пешерсә икән, дип эчтән тагын бер кат хыялланып куя.

Пекарня 1945 нче елдан бирле халыкка хезмәт күрсәтә. Бирелә 4 бригада—дүрт сменада эшли. Тәүлегенә 2 тонналан артык, ә аеруча кирәк вакытта (менә хәзерге кебек, колхозлар өчен пешергәндә) ике тапкыр артыграк җитештерәләр. Бригадирлар—Г. Иляллова, Н. Сабирова, Г. Минехәерова, Н. Хәярова. Аеруча Гөлфия Иляллова бригадасын һәм анда ипи пешерүчеләр Зөлфия Бикинеева һәм Мәдинә Мәүлетованы мактап телгә алалар.

Әйе, ипи пешерү, бигрәк тә шундый тәмлене—ул изге хезмәт.

# Сәләкгештә шулай эшлиләр



Һәр елны шулай: Владимир Алексеевич ДТ-75ен куя да бөртек суктыру комбайнына утыра. Һәр кырның йөзен, һәр культураны җыюның үзенчәлеген ул биш бармагыдай белә. Озак елларга сузылган хезмәт аңа тәҗрибә, осталык кына түгел, авылдашлары арасында ихтирам да китерде.

**Владимир Алексеевич** Сапожников быел да «Нива» комбайнында кырлар иңли. Ярдәмчесе С. Кузнецов белән игеннәрне тезэмнәргә салуда, суктыруда әйбәт кенә нәтиҗә күрсәтеп эшлиләр алар. «Родина» колхозында ужым культураларын җыю үзвакытында тәмамланды. Инде Сапожников экипажы сабан бодаен тезэмнәргә сала.

Рәсемдә: «Родина» колхозы механизаторы В. А. Сапожников.

Әле кайчан гына яшел дулкын булып чайкалып утырган иген кырларына сары, кара төс иңеп килә. Моңсурак күренеш булса да, авыл кешесе бу үзгәрешне шөкерана кылып кабул итә: шөкер, игеннәр кулга керде, шөкер, басулар киләсе уңыш өчен әзерләнә.

«Заветы Ильича» колхозы эшчәннәре дә шулай уйлый. Июль буе авыл халкы кырдан кергән хәбәрләрне тыңлап яшәде: «Теге басуда быел гына пәйда булган мәһабәт «ДОН-1500»дә эшләүче аталы-уллы Юрий һәм Сергей Гордюниннар 4 мең центнердан артык ашлык суктырганнар. Узган ел колхозда беренче урынны яулаган Александр Николаевич Корнеев быел да алдынгы урыннарның берсенә исәп тота икән. Партоешма секретаре Анатолий Харисанович Ворков улы белән икесенә ике комбайн алып эшлиләр, һәр икесе дә алдынгылар рәтендә бара. Павел Александрович Корнеев урудa да, суктыруда да бердәй җитезлек белән эшли икән». Комбайннарның ярты көнгәчә сузылган гөрелтесе авылда кайтаваз булып шулай яңгырады.

Болар һәммәсе бүген артта калды. Соңгы көннәрдә хуҗалыкта солыны тезэмнәргә салалар, арпа, бодай өлгергәнне көтәләр һәм көзге эшләрнең иң мәшәкатьлеләре—җир әзерләү, туңга сөрү белән шөгыльләнәләр, салам өяләр. Соңгысы белән Сергей Константинович Маринин җитәкчелегендәге азык әзерләүчеләр звеносы мәшгуль. Звено әлегә кадәр 526 тонна печән, 2348 тонна сенаж әзерләгән. Инде аларның бер өлеше ужым арышы кырында салам җыя. Звено җитәкчесе Сергей Константинович үзе ничә еллар инде шәбен өне алып бара. Тракторчылар Анатолий Николаевич Белогубов, Геннадий Аркадьевич Трофимов, Александр Кузьмич Творогов саламны тарттыру, җыю белән мәшгульләр.

—Быел саламга иркен, —диләр механизаторлар.— Үзебезгә дә җитә, кирәк очракта ярдәм итү мөмкинлегебез дә булачак. Шуңа ук укучылар биегрәк калган камылларны яндыралар. Сузарга ярамый, чөнки саламнан арындырылган басуга шунда ук сөрү техникасы чыга. Быелгы урак туңга сөрүне бик иртә башларга җай бирде. Сәләнгешләр моңа куаналар, чөнки август—туңга сөрүнең иң оптималь срогында аның төп өлешен бетерергә аларның ниятләре. Ә сөрү мәйданы аз түгел—1500 гектар. Механизаторлар быел бик бердәм керештеләр бу эшкә. Туңга сөрү ике сменада алып барыла: иртәнге 6дан кичке алтыга кадәр һәм киресенчә.

Быелгы туңга сөрүнең үзенчәлекләрен һәр механизатор әйбәт аңлый.

—Сөрү тирәнлегенә игътибар бирәбез, ел корылыклы бит. Өстәвенә, киләсе елда бирегә чөгендер чәчеләчәк, сөрүне аерата сыйфатлы башкарырга кирәк.

Бу сүзләрне Николай Константинович Белогубов әйтә. Таныш фамилия дисезме? Әйе, нәкъ салам җыюда эшләүче Белогубовның әтисе. 30 елдан артык тракторчы булып эшли инде ул. Җирнең әллә нинди сыкраган елларын күргән, исәнлеген шунда куйган. Быелгы туңга сөрү дә җиңел түгел. Корылыктан җир ярылган, төрәннәр авыр йөри. Андый чакта яшьрәкләр Николай Константиновичның һәм аның кордашлары кебек өлкән механизаторлар тәҗрибәсенә таяналар. Әнә Николай Васильевич Тимохин да шул чор кешесе, 30 елдан артык механизатор.

—Кордашлардан бишләп механизатор калдык,—ди ул.—Калганнары яшьләр. Безгә дә тиздән постны бирергә җитә инде.

Колхоз рәисе А. И. Баранов аларның кәефләрен күтәрергә тырыша:

—Юк әле, бер дигән эшлисез.

Анысы хак. Бу буын механизаторлар дисциплина, хезмәткә җаваплы караш белән аерылып торалар. Хәер, туңга сөрүдә эшләүче яшьләргә дә тел теш тидерерлек түгел. Әнә газовик Сергей Андреевич Оськин һәр елны җәй көннәрендә тракторга утыра, бер дигән эшли. Виктор Григорьевич Исаев та көнлек норманы 2—2,5 тапкыр арттырып үти. Владимир Геннадьевич Чаловны күрсин, эшенә карап торуы да рәхәт бит. Хәер, Чаловлар башкача эшләргә тиеш тә түгел әле ул. Бу—нәселдән механизаторлар династиясе. Өлкән Чалов—Геннадий Яковлевич гадәттә экскаваторда эшли, аннан чөгендер комбайнына күчә. Ә кече уллары Михаил азык әзерләүчеләр звеносында. Шулай механизатор эшен гаилә һөнәре иткән кешеләр аз түгел биредә. Кырдагыларга аш әзерләүче А. А. Корнеева горурлык белән сүзгә кушыла:

—Ике улым колхозда калды, икесе дә механизатор.

Шулай икән шул. Өлкәне Александр МТЗ--80не җәй көнне бөртек комбайнына алыштыра. Ә Сергей шундый ук техникасын куеп азык җыю комбайнына утыра. Быел азык катнашмалары җыюда эшләде, инде техникасын кукуруз уңышын алырга әзерли.

Әйе, механизаторга җәен эш бетми. Игеннәрдән бушаган кырларга алар керә, ужым культуралары чәчеләчәк мәйданнарны әзерләү дә тулы куәтенә бара. Быел ужым культураларына 900 гектар җир каралган. Павел Тришин Т-150 һәм Иван Аркадьевич Ворков К-700 тракторларында җир әзерләү белән мәшгульләр. Азык катнашмалары, борчактан бушаган мәйданнар бүгеннән чәчүләрне кабул итәргә әзерләр. Хәер, чәчү өчен дә һәммә нәрсә — тракторлар да, чәчкечләр, төягечләр дә әзерлек сызыгында. Быел ужым чәчәргә чыгачак Иван Федорович Пылаев та ярышка җыенган ат кебек күрсәтмә булганны гына көтә. 10 августта сәләнгешлеләр чәчүне башларга уйлыйлар.

Әнә шулай ничәмә-ничә төрле эш, ничәмә-ничә төрле мәшәкать авыл эшчәннәре башында. «Заветы Ильича»колхозында да нәкъ шулай. Бәхеткә, әлеге хуҗалыкның тынгысыз эшчәннәре һәр хезмәтне читтән ярдәм көтмичә, җай белән, каударланмыйча, шул ук вакытта тезгенне дә бушатмыйча сыдырып эшләргә гадәтләнгәннәр. Бу күрдәм гадәт һәр җирдә күзгә ташлана.

...Басулар янә трактор гөрелтесенә күмелә, җиргә сары-кара төс иңә.

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**
«Заветы Ильича» колхозы.

# Хезмәтләре күз алдында

Рейд бригадасы шәһәрнең икмәк заводына килгәндә әзер продукцияне кибетләргә озату өчен машинага төйиләр иде. Машина (02—19 ТБА номерлы, шоферы—Ринат Билданов) иртәнге рейска гына чыгуга карамастан, аның эчендә элекке көнне коелган ипи валчыклары себерелмәгән булып чыкты. Ипи куела торган киштәләр дә күптәннән инде чистартылмаган. Икмәк заводы директоры В. Н. Кузнецовның әйтүенчә, махсус килешү нигезендә, ипи ташучы машиналарның чисталыгы өчен АТП җавап бирә икән, ә калган җиһазларның (алынмалы киштәләр һ.б.) чисталыгы өчен завод җаваплы.

Завод цехлары, андагы хезмәт һәм көнкүреш шартлары канәгатьләнерлек иде.

**Корреспондент фикере. Дөрес, юып кына алынган идәннәр, эшләүчеләрнең чиста киемнән булуы, цехтагы тәртип никадәр күңелгә ятышлы булса да, бераз шикләнүгә дә урын калдырды. Рейд көнен алдан белеп, «итәк-җиңне җыебрак» тору галәмәте түгел микән бу? Әллә көн саен алар шушы дәрәҗәдә микән? Чөнки заводка барып кергәч: иптәш Хәсәншинаның: «Җитәкчегез мондамы?»,—дигән соравына каршы, производство мөдиренең уйлап тормастан гына: «Ул сезне көтте, көтте дә китеп барды»,—дигән җавабын ишетергә туры килде. Хәер, бусы инде бүтән мәсьәлә... Менә шулай дөреслек, яхшылык, гаделлек эзләп, аз булса да гомум эшкә файда булсын дип чыккан рейдларда юлдашларыңның икейөзлелегенә, профессиональ хыянәтенә, санга сукмавына тап булу бер дә күңелле хәл түгел.**

Лаборатор тикшерү нәтиҗәләре заводта (ул көнне беренче һәм икенче сортлы оннан) пешерелгән икмәкнең ГОСТ таләпләренә туры килүен, авырлыгы да тиешенчә булуын күрсәтә.

Җитештерү процессында аерым кимчелекләргә күрсәтелде. Аларның бер өлеше заводның иске бинада булуына бәйле. Шуңа күрә, заманча тиешле шартлар булдыру өчен янәшәдә үк нигез салынып килгән яңа заводны күтәргә туры килә. Әмма бүгенге шартларда ук үтәп булырдай кимчелекләр дә юк түгел. Әйтик чималның (онның) саклануы дөрес түгел. Икмәк ташый торган транспортның һәм җиһазларның чисталыгына ирешергә кирәк.

Бу көннәрдә заводның бер мичен план буенча сыек ягулыкка күчерү сәбәпле ипи бер генә мичтә пешерелә иде. 1 мич тәүлегенә 9 тоннадан артыграк продукция бирә. Һәм ул 20 ләп кибеткә озатыла. Тиздән икенче мич тә эшли башлаячак.

Завод янында ук матур итеп буялган кечкенә генә бер ларек тора. Эчендә киштәләре, тәрәзәсе бар. Аның баскыч алдында берничә кеше койма рәшәткәләрен көйләп йөри. Якын арада завод монда кайнар икмәк сата башларга ниятли. Нәкъ шулай: «Кайнар ипекәй» дип исемләргә уйлыйлар. Мичтән чыккан хуш исле икмәкне шунда ук сатып алучыга тәкъдим итәчәкләр.

Гомумән, заводның эше уңай тәэсир калдыра. Ә продукциясе—һәр көнне сезнең, безнең табын түрендә, кадерле укучыбыз. Аңа иң гадел, иң таләпчән бәяне син үзең куясың.

**Ф. ХӘСӘНШИНА,**
туклану гигиенасы буенча санитар врач ярдәмчесе.

**Л. КУЗНЕЦОВА,**
врач-химик.

**К. ҖАМАЛЕТДИНОВА,**
редакция корреспонденты.

# Саламга кытлык булмас

«Восход» колхозында быел күтәренке кәеф белән эшлиләр. Әйбәт кенә барган бөртекле культураларны суктыру белән параллель рәвештә салам тарттыру эшләре дә бара. Биредә Т-150 тракторы белән Петр Анисимов тырышлык күрсәтә. Ул туган авылына чәчүгә дә, урып-җыю чорына да УТТда эшләгән җиреннән кайтты. Шулай ук Т-70 тракторлары белән Николай Нагорный һәм Сергей Сергеев та салам тарттыруда фидакарь хезмәт күрсәттеләр. Елның коры килүенә карамастан, биредә кырлар саламга бай күренәләр.

—Әйе, бездә дымлы туфрак,—дип аңлата моның сәбәбен колхоз рәисе В. В. Тарасов.—Салам проблемасы булмаячак. Хәтта ихтыяҗы булганнарга бераз ярдәм итәргә дә мөмкинлегебез бар,—ди ул.

**Ф. ВӘГЫЙЗОВА.**

# Безнең Миннур

Соңгы вакытта почтальоннарның хезмәте икеләтә авыр. Чөнки газета-журналларның төрле исемдәгеләре чыгарыла башлады. Пенсионерларга пенсияне дә алар өләшә. Радио-телевизор аша яңалыкларны тыңласак та, аңа гына канәгатьләнмибез. Илебездәге үзгәртеп кору чоры үзгәрешләргә бик бай, шуңа күрә түземсезлек белән газета-журналларны көтеп алабыз. Нинди генә мәшәкатьле чагыбыз булса да газетаның һәр мәкаләсен игътибар белән укыйбыз. Ә инде без—пенсионерлар, пенсияне тагы да түземсезлек белән көтәбез, чөнки бер айның пенсиясен икенчесе күрми, әҗәткә керәсең. Әмма безнең хат ташучыбыз Миннур Абдрахимова матбугатны да, пенсияне дә үз вакытында китереп җиткерә. Алай гына түгел, хатны салыргамы, радиога акча түләргәме—ул авырсынмыйча безнең үтенечне үти. Аның йорттан-йортка ашыга-ашыга йөрүен күрәсең. Чөнки ул халыкка газета-журналларны, хатларны тизрәк илтеп җиткерергә ашыга. Шуңа күрә без аны хөрмәт итәбез, ул безгә чит түгел, үзебезнең Миннур.

Аңа гаиләсендә, эшендә тынычлык, тагын да зур уңышлар телибез, шулай ук рәхмәтебез дә чиксез.

**Д. САТДАРОВА.**

## Ил буенча

СТАВРОПОЛЬ. Гарәп токымлы чабышкы атлары шушы көннәрдә «Терский» ат заводыннан чит илләргә озатылды. Алар барысы да валютага Германия, Голландия, Италия, Сүрия, Швейцария эшкуарларына сатылды. Моннан кергән табыш бу юлы 100 мең доллардан артып китте.

x x x

СССР Кораллы Көчләренең үзәк музеенда Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләргә сугышчан орденнар һәм медальләр тапшырылды. Үзләренә тиешле бүләкләрне төрле сәбәпләр аркасында алар хәзергәчә ала алмаган булганнар.

x x x

Былтыр гына да СССР Оборона министрлыгының баш кадрлар идарәсе вакытында үзләренә тиешле бүләкләрне алмаган 70 мең ветеранны ачыклады.


# Кич утырганда

## Укучыларыбыз иҗаты

**Роза Мәсләхова**

### Җәйге иртә

Кояш нуры ача җирнең
Яулыгы читен.
Уянып китә табигать,
Юына битен.
Тыныч күкләрне балкыта
Кояшның нуры.
Шушы түгелме икән соң
Бәхетнең зуры?
Бар уяуны сөендерә
Кояш балкышы.
Башлана табигать җыры,
Җирнең алкышы.
Яфрак очларыннан энә
Энже чык тама.
Әйтерсең, табигать үзе
Бәхеттән таша.
Ямьләп җиргә җәй иртәсен
Сайрый сандугач.
Бизәкләргә күмеп күкне
Оча карлыгач.
Тагы да көчлерәк аңкый
Чәчәкләр исе,
Бал кортларын җәлеп итә
Аларның хисе.
Сафланыр күңелең синең,
Өстәлер көчең,
Кабатланмас мизгел бит бу,
Уян син, кешем!



Туган авылым, туган нигез шулай Төшләремә кереп йөдәтә...

**Мөнәвәрә Усманова**

### Кичектең инде

*Яшьли тол калган укытучы дустым М. га багышлана.*

...Син дә ут күбәләк кебек
Ялтыр утны чәчәк диеп,
Тирәсендә очтың биеп,
Һәм соңыннан төштең көеп.
Нигә кабат чыктың юлларыма
Газапларга салып җанымны,
Нигә кирәк булды яңартырга
Йомылып барган йөрәк ярамны.
Кичер, зинһар, диеп өзгәләнмә,
Кабат булмә барыр юлымны,
Хыянәтче җан син! Ташлап киттең
Яңа туган нәни улыңны.
Озак көттем сине... Төннәрендә
Ничә кабат елап уяндым
Һәм гөнаһсыз газиз сабыемны
Күкрәгемә кысып юандым.
Сыңар канат каерылды канап,
Очар чакта бәхет таңыма.
Бик кичектең инде, өзгәләнмә,
Саф җаныма кабат кагылма.
Синнән башка бер кемем юк, дисең,
Ялгыз, дисең, көнем-төннәрем...
Кая олактылар дистәләгән
Сәрхүш-җанкай, әллә кемнәрең...
Яшең олыгайган, җаның арган,
Юмарт чибәрләрне яратып.
Бик соңладың инде, өзгәләнмә,
Йөрәк яраларын яңартып.
Саф йөрәгем мәңге кабул итми,
Рөхсәтем юк, чыкма юлыма.
Малаеңның газиз улы туды,
Теләсәң кил бәбәй туена.

## 01 хәбәр итә

22 июльдән 29 июльгә кадәр районда өч янгын булды.

25 июльдә Норлатта яшәүче Р. Бикиевның шәхси гараж түбәсеннән ут күтәрелде. Үзвакытында янгын сүндерүчеләрнең килеп җитүе аркасында гаражны коткарып калдылар. Янгын чыгу факты буенча тикшерү алып барыла.

Шул ук көнне электр үткәргеченең төзек булмавы һәм өйдә генә ясалган саклагыч куллану аркасында Бикүле авылында яшәүче Г. Кәлимуллина йортында янгын чыкты. Нәтиҗәдә йорт җиһазларының бер өлеше янды.

27 июльдә «Чирмешән» колхозында электр үткәргечләрнең һава линиясе өзелеп төшү сәбәпле салам кибәненә ут капты.

Барлык очракларда да районның янгынга каршы көрәш службасы зур тырышлык күрсәтте.

**Ә. ЭЮПОВ,**
дәүләт янгын күзәтчелеге инспекторы.

## Картлык

Иске йортта ялгыз карчык
Әй сукырана.
Нинди ачы язмыш соңы
Язылган аңа.
Язмышыннан сукырана,
Елый бичара.
Тәкъдиреннән узалмагач
Итсен ни чара.
Гөрләп торган якты йортта
Яшәгән иде.
Күрегезче, ул йорт нигә
Әйләнгән инде.

Үзе яшь тә, чибәр, таза,
Уңган да иде.
Инде гомер көзе җитте,
Картлыгы инде.
Хәзер инде бөкерәйгән,
Сап-сары йөзе,
Бик авырлык белән генә
Атлый ул үзе.
Кайчандыр чатырдай яулык
Инде каралган,
Ялгыз картлык белән шулай
Нигә каргалган?

Шул ялгызаклар янына,
Зинһар, керегез,
Ярдәм итеп, иренмичә,
Хәлен белегез.
Белмибез бит нинди картлык
Килеп җитәсен,
Бу дөньядан картлар безне
Каргап китәсен...
Карт-корылар рәхмәт укып
Догасын кылсын.
Үзебезгә дә бу язмыш
Рәхимле булсын.

**Тимерша ВАХИТОВ.**

x x x

Килер юлларыңа
күз текәдем...
Яшим күз карашың
сагынып—
Бер кош булсам,
Күптән очар идем
Син яшәгән якка,
Кагынып...

x x x

—Нихәл, туган! Дөнья
ни хәл?
...Җанга көрәшү кирәк—
Чынлап яшик дисәк җирдә
Хәлләр белешү кирәк...

## ХАЛЫК ИГЪТИБАРЫНА!

Октябрь райпо заготпромы быел баш су... 1 килограммын 1 сум белән кабул итә.

02 хәбәр итә

# Хокук тәртибен бозу кимеми

Беренче ярты ел йомгакларын күз алдыннан үткәргәннән соң, районда җинаятьләр эшләнү һәм аларның саны элекке еллар белән чагыштырганда шактый артуы күзәтелә. Мәсәлән, узган елның беренче ярты елында районда 113 җинаять очрагы теркәлсә, быел ул 160тан да артып китте. Шуларның 37 се авыр (ягъни үтерү, көчләү, талау һәм башка) җинаятьләр. Бүлек тарафыннан даими рәвештә профилактик чаралар үткәрелүгә карамастан, шәхси һәм дәүләт милкен урлау очраклары да кызу темплар белән арта бара. Мәсәлән, узган ел беренче яртыеллыкта 28 җинаять очрагы теркәлгән булса, быелгы алты айда инде ул сан 51 гә җитте. Эчкән килеш җинаять эшләү дә арта бара. Ул барлык җинаятьләрнең 43 процентын тәшкил итә. Хулиганлык очраклары да көннән-көн ешая. Алар күпчелек очракта эчкән килеш эшләнәләр. Быел шундый 30 очрак теркәлгән. Җаваплылыкка тартылучылар саны былтыргы беренче ярты еллыкта 57 булган булса, быелгы алты айда 71 гә җитте.

Төрле сәбәпләр аркасында эшләмәүчеләр саны шулай ук айдан-айга арткан.

Менә быелгы алты айда шундыйлар тарафыннан 11 җинаять эшләнгән, (ә узган елгы шушы чорда мондый 7 очрак булган).

Урыннарда үткәрелгән тикшерүләргә нигезләнеп, шуны әйтергә мөмкин: җинаять эшләүчеләр белән коллективларда администрация, профком һәм башка җәмәгать оешмалары бөтенләй шөгыльләнмиләр. Тәрбия эше үз агымына, үз иркенә куелган җирләрдә аның «уңышы да мул». Мәсәлән, Норлат шикәр заводында элеккерәк елларда профилактик тәрбия чаралары даими оештырыла иде. Ә хәзер коллективта хокук бозу очраклары ешайды һәм бу беркемне дә борчымый да кебек. Мәсәлән, быелгы алты айда монда вак хулиганлык очрагы 23 кә җиткән, эш урынында эчеп яту очрагы 8 һәм көмешкә куу 2 тапкыр һәм 11 җинаять очрагы теркәлгән.

Хокук бозу очраклары ягыннан шәһәребездәге бер генә оешма һәм предприятие дә бу коллектив белән ярыша алмый. Ярый әле аларга капма-каршы куярлык—ярты ел дәвамында бер генә хокук бозу очрагы да булмаган 53 нче төзү-монтаж идарәсе коллективы бар.

**Р. ТӘМАЕВ,**
Октябрь район эчке эшләр бүлегенең профилактик служба бүлеге начальнигы.




Киекле авылында яшәүче этиебез Нәбиулла Хөснулла улы ХӘЙРУЛЛИНны 60 яше тулуы белән котлыйбыз. Аңа нык сәламәтлек, шат көннәр телибез.

**КЫЗЫ, КИЯВЕ, ОНЫКЛАРЫ.**

x x x

Норлатта яшәүче кадерле кызым, тормыш иптәшем, әниебез Гөлмиҗамал Мәрдегалим кызы ХӘЙРУЛЛИНАга 65 яшь тула. Аңа нык сәламәтлек, озын гомер, тынычлык телибез.

**АТАСЫ, ТОРМЫШ ИПТӘШЕ, КЫЗЫ, КИЯВЕ ҺӘМ ОНЫКЛАРЫ.**


МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.

Учредительләр халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере диган сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 93. Тираж 3415.